ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.11.2022 — с. Кильдеево — 30

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә Борнаш авыл җирлегенең гражданнар җыенында кабул ителгән 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты

карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы — Бурдин В.М.

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
2022 елның 29 ноябреннән
30 номерлы карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнардан
үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Килди авылы торак пункты территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели:

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан тавыш биргәндә белдерелгән гражданнар җыенында катнашуга һәм мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) 1 төркем инвалидлар

б) тыл хезмәтчәннәре

в) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның хатыннары һәм катнашучылары

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты счетына керә.

6. Гражданнар түләүләре физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукы булган оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама буенча https://uslugi.tatarstan.ru/күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслау - приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
2022 елның 30 ноябреннән
30 номерлы карарына

2 кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге бюджетына үзара салым
буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф. И.О.
__________________________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
__________________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________________ вакытына кадәр
___________________________________________________ чараларны тормышка ашыру
өчен _____________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча: __________________________________________________
бер тапкыр акча түләргә кирәк.
Алучының банк БИК ______________________________________
Сч. № __________________________________
Алучының сч. №__ . _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО__________________
Түләүне билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. п. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында _______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.О _______________________________________________________
Адрес:
__________________________________________________________________________
Алдым "__" _________________ 20___ ел. ______________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Әгәр дә хәбәр түләүчегә шәхсән бирелсә, аермалы корешок тутырыла һәм ________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*